СОВЕТ
СИЗИНСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д. 1, с.Смак-Корса,
Арский муниципальный район, 422025

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СЕЖЕ
АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
СОВЕТЫ
Мәктәп урамы, 1 йорт, Курса Почмак авылы,
Арча муниципаль районы, 422025

Тел. (84366)93-1-24, факс (84366)93-1-24. E-mail: Smk.Ars@tatar.ru

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

## КАРАРЫ

**30 октябрь 2023 ел** **№ 11**

**Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Яңа Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Яңа Чүриле авылында Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 53 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 22 ноябренә 10 сәгать 00 минутта халык җыенының беренче этабын билгеләргә.
2. Арча муниципаль районы Сеже авыл җирлеге Яңа Чүриле авылында Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 53 йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 22 ноябренә 16 сәгать 00 минутта халык җыенының икенче этабын билгеләргә.

3. Торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген бүлүне территория буенча башкарырга.

1нче этап: Сергин урамында яшәүчеләр

2нче этап: Мәктәп урамында яшәүчеләр.

4. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне раславга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Яңа Чүриле авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 250 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, 1нче группа инвалидлардан һәм 80 яшьтән узган гражданнардан тыш, 500 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

-урамнарны яктырту челтәрләрен ремонтлау, шул исәптән яктырткычлар, лампалар, изоляцияләнгән чыбыклар, таймерлар, автоматлар, контакторлар сатып алу һәм урнаштыру;

-вак таш сатып алу һәм китерү, Сергин һәм Мәктәп урамнары буенча җирле әһәмияттәге юл-урам челтәренең йөрү өлешен вак таш белән өлешчә тигезләү ;

- бензин генераторын сатып алуны финанслашу;

- МТЗ 82.1 тракторының асылмалы җиһазы чапкыч өчен пычаклар комплекты сатып алуны финанслашу ;

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

5. Арча муниципаль районы Сеҗе авыл җирлеге Яңа Чүриле авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Сеҗе авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

6. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Яңа Чүриле авылы, Сергин урамы, 53 йорт йорт, адресы буенча ;интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

7. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Сеҗе авыл җирлеге башлыгы Р.В.Хәмидуллин